ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

«11» октябрь 2022 ел Шилнәбаш авылы № 3

**«Тукай муниципаль районы Тогево авыл җирлеге Шилнәбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Тогаево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башлыгының 2022 елның 30 сентябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктын өстәп, үзгәрешләр кертергә:
«2.1. Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.».
2. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы О.А. Гончарова

Исполнительный комитет ШИЛЬНЕБАШСКОГО сельского поселения
ОГРН 10616820497
ИНН 1639032400